| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

11.12.2019 — Казан шәһәре — № 5-104/тэ

«Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2020 елга тарифлар билгеләү хакында

"Җылы белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында" 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең "Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында" 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» МУП) тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә), әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. — Л.П. Борисова

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 5-104/тэ карарына кушымта

## «Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2020 елга календарь буенча бүлгәләнгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Питрәч муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1618,31 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1682,71 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге